| Республика Татарстан<br>Зеленодольский<br>муниципальный район<br>Исполнительный комитет<br>Нижневязовского городского<br>поселения | Татарстан Республикасы<br>Зеленодол муниципаль<br>районы<br>Карамалы тау шэһэр<br>жирлеге башкарма<br>комитеты |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.03.2018**

Карамалы Тау штп

**КАРАР**
**№09**

Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау ш.т.б.» муниципаль берәмлеге территориясендә «Торак-2018» янгын-профилактик операциясе үткәрү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елда Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә «Торак-2018» янгын-профилактик операциясе үткәрергә.
2. Торак фондта янгын-профилактика һәм агитация эшләрен үткәрү өчен составтагы оператив профилактик төркем төзергә:

Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Вяткина Анна Валерьевна;

154 нче янгын часте хезмәткәре (килешү буенча);

Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәре (килешү буенча);

«Зеленодольскгаз» ЭПУ, «Карамалы Тау жилкомсервис» ҖЧҖ, «Йорт идарәсе» ТСЖ һәм башка як оешмалары хезмәткәрләре (кирәк очракта).

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә, шулай ук Карамалы Тау шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча урнашкан: Карамалы Тау ш.т.п., Беренче Май ур., 70

йорт, Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының административ бинасы.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Җитәкчесе** **А.М. Гыйниятов**